**Кукмара муниципаль районы**
**Зур Кукмара авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**«30» март 2022 ел** **№ 7**

«2022 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авылы территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2021 елның 5 декабрендәге 44 номерлы гражданнар җыены карарын үз көчен югалткан дип тану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авылы бер өлешендә гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә Зур Кукмара авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 11 апрелендә 10 сәгать 00 минутка «2022 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авылы территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2021 елның 5 декабрендәге 44 номерлы гражданнар җыены карарын үз көчен югалткан дип тану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

Гражданнар җыенын Зур Кукмара авылының Эшчеләр урамында 9 нче йорт янында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда Кукмара районының Зур Кукмара авылының Эшчеләр урамында территориясе өлеше чикләрендә гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2021 елның 5 декабрендәге 44 номерлы гражданнар җыены карарын үз көчен югалткан дип тану белән килешәсезме?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы Р.Р. Хәнәфиев